**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

«26» май 2026 ел.

Ачык тыңлаулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы Карары белән расланган (Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 декабрендәге 96-РС номерлы Карары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә, Татарстан Республикасы Кабинет Министрлыгының 2023 елның 29 декабрендәге «“Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 1743 номерлы карары нигезендә — кешенең уңайлы яшәү шартларына булган хокукларын, җир участоклары һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатыннан уздырылды.

Ачык тыңлаулар Сокуры авыл җирлегенең бөтен территориясенә карата уздырылды.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлауларны уздыру вакыты, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру вакыты һәм урыны, ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 6 маендагы 4186/исх номерлы белдерүе аша хәбәрдар ителде.

Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар башлану турындагы 2026 елның 6 маендагы 4186/исх номерлы белдерү түбәндәгечә бастырылды (халыкка җиткерелде):

2026 елның 7 маенда — Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында;

2026 елның 8 маенда — Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Камская новь» («Кама ягы») газетасында;

2026 елның 8 маенда — Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Карсалов Алексей Петрович — Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.

Ачык тыңлаулар сәркатибе: Мәүлиев Радик Рәшит улы – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге башлыгы, башкарма комитеты җитәкчесе.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы нәтиҗә (заключение) Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 2026 елның 25 маендагы ачык тыңлаулар протоколы нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 14 кеше катнашты.

Ачык тыңлаулар барышында кергән сораулар һәм искәрмәләр.

| **№** | **Катнашучы турында мәгълүмат** | **Сорау, искәрмә, тәкъдим тексты** | **Җавап тексты** |
|---|---|---|---|
| 1 | Индивидуаль эшмәкәр крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы И.Г. Дияров | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 06.04.2026 елдагы 643/о санлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы “Сокуры авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектына әзерлек турында»гы боерыгы нигезендә ачык тыңлаулар уза (ачык тыңлаулар башлану турында хәбәрнамә: 06.05.2026 ел, №4186/исх). Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү кысаларында, сездән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең генераль планы проектына кадастр номерлары 16:24:240303:8424, 16:24:240303:8403, 16:24:240303:6328 булган җир участокларында урнаштыру планлаштырылган 120 урынлык мәктәпкәчә мәгариф учреждениесен һәм спорт комплексын җирле әһәмияттәге объектлар составына кертү өлешендә үзгәрешләр кертүегезне сорыйм. | Бу искәрмәне исәпкә алу максатка ярашлы. |
| 2 | Индивидуаль эшмәкәр крестьян | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 06.04.2026 елдагы 643/о | Исәпкә алу максатка ярашлы түгел.Генераль план проектындагы автомобиль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (фермер) хуҗалыгы башлыгы И.Г. Дияров | санлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы “Сокуры авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектына әзерлек турында»гы боерыгы нигезендә ачык тыңлаулар уза (ачык тыңлаулар башлану турында хәбәрнамә: 06.05.2026 ел, №4186/исх).Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү кысаларында, сездән кадастр номерлары 16:24:240301:1746, 16:24:240301:5392 булган җир участокларында урнаштыру планлаштырылган түбәндәге исемнәрдәге авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары трассировкасын үзгәртү өлешендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең генераль планы проектына үзгәрешләр кертүегезне сорыйм: Автомобиль юлы №19.9, Автомобиль юлы №19.10, Автомобиль юлы №19.11, Автомобиль юлы №19.12. | юллары трассировкалары ориентация өчен (чама белән) генә бирелә һәм алар генераль план расланганнан соң, аны гамәлгә ашыру этабында билгеләнә. Бу очракта инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре исәпкә алына, ә аннары территорияне планлаштыру документациясе һәм (яисә) бер яки берничә сызыклы объектны урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру документациясе эшләнә. |
| | | | |

**Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:**

1. Ачык тыңлауларны узган дип танырга;
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, 2026 елның 25 маендагы ачык тыңлаулар протоколын, шулай ук әлеге нәтиҗәне (заключение) проектны тулысынча раслау өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрергә;
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге нәтиҗәдән өземтәләр (выпискалар) бирүне гамәлгә ашырырга.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар сәркатибе __________________________ Кондратьева А.А.